УДК 070.11

**И.И. Фазлутдинов**

# «ТУЛПАР» ЖУРНАЛЫНДА ӘДӘБИ ЖАНРЛАР

***Аннотация:*** *В данной статье автор анализирует основные жанрово-тематические направления литературно-художественного журнала «Тулпар». Особый упор делается на литературные жанры – повести, рассказы, стихотворные подборки, литературные интервью и критику. Исследуются принципы их рубрикации, дается обзор основных авторов и произведений.*

***Ключевые слова:*** *журнал, литература, направление, поэзия, проза, рубрика, литературная критика.*

1994 елда «Тулпар» журналы нәшер ителә башлау белән, редакция үз эшчәнлегенең дүрт төп юнәлешен билгели. Бу – әдәбият, мәдәният, яшьләр һәм заман. Бу юнәлешләр бүгенгә кадәр үзгәрешсез кала.

Әлеге «буразналар» хакында журналның беренче баш мөхәррире Римат Кашапов түбәндәгеләрне яза: «Беренче һәм төп буразнабыз, әлбәттә, нәфис әдәбият иде. Бәлки, гаҗәп тоелыр: без журналның беренче саннарыннан ук диярлек чәчмә әсәрләргә дә, шигъри шәлкемнәргә дә кытлык кичермәдек. Хәбәре таралу белән Башкортстанның гына түгел, илнең төрле төбәкләреннән әдәби әсәрләр агыла башлады.

Мәдәният дөньясы икенче буразнабыз булды – сәнгатебез, мәгърифәтебез, динебез, йолаларыбыз аша укучыларыбызга маяклар күрсәтү. Өченче буразнабыз, әлбәттә, гомернең иң саф, якты һәм гүзәл мизгеле – яшьлек иде. Һәм дүртенче, гаять җаваплы буразнабыз – заман үзе булды. Публицистик мәкаләләр, уйланулар аша чорыбызның катлаулы сәяси һәм икътисади проблемаларын, аларның милләтебез киләчәгенә йогынтысын күрсәтүне максат иттек.

Укучыларыбыз ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү максатында хатын-кызларга – «Ак калфак», балалар өчен «Тузганак» кушымталарын булдырдык. Хикәяләр бәйгесен һәм «Агыйдел сылуы» фотоконкурсын игълан иттек» [1; 2-3].

Башкортстандагы бердәнбер татар телендәге журнал буларак, нәшер ителә башлаган көненнән үк «Тулпар» әдәби, хатын-кызлар, яшүсмерләр һәм юмористик басмаларның асылын берләштерергә тиеш була. Шулай итеп, журнал составында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тузганак», хатын-кызларга тәгаенләнгән «Ак калфак», сатира һәм юмор сөючеләр өчен «Кызык-мызык» сәхифәләре барлыкка килә.

Хәзер инде сүзебезне журналда төп урын алып торган әдәбият юнәлеше буенча дәвам итик. Аларның һәркайсына караган рубрикалар, һәр юнәлешнең структурасы 1994 елның икенче яртыеллыгында формалашып бетә.

Әлеге юнәлешкә «Чәчмә әсәр», «Шигърият», «Әдәби тәнкыйть», «Киштәдә яңа китап», «Әдәби кунакханә», «Илһамлы каләм», «Укучылар иҗаты», «Иҗат берләшмәләрендә», «Кызык-мызык», «Әдәби мохит» рубрикалары карый. «Чәчмә әсәр» рубрикасы астында һәр номерда бер зур проза әсәре, нигездә, повестьлар, 2-3 хикәя басыла. «Шигърият» рубрикасында сан саен 4-5 шигъри шәлкем урнаштырыла, «Кызык-мызык» сатира-юмор сәхифәсе журналның 4 битен алып тора һәм вак материаллардан, карикатуралардан төзелә. «Әдәби тәнкыйть», «Әдәби кунакханә» рубрикалары астында, гадәттә, сан саен бер материал урнаштырыла. «Киштәдә яңа китап» рубрикасының күләме 1-2 колонка белән чикләнә һәм ул Башкортстанда чыккан татар телендәге әдәби китаплар белән таныштыра. «Әдәби мохит» рубрикасы исә шулай ук кечкенә күләмле, һәм ул әдәбият дөньясында соңгы ике айда дөнья күргән яңалыкларны укучыга җиткерә.

Әдәби әсәрләрне басканда, «Тулпар» үз юлы белән китә. Төп игътибарын ул Башкортстанда яшәп татар телендә иҗат итүче язучы һәм шагыйрьләргә бүлә. Аларга журнал битләрендә дә урын түрдән була. Бу кагыйдә әле дә үзгәрешсез кала. Шул ук вакытта, «Тулпар»чылар Татарстанда яшәүче иң күренекле татар әдипләренең һәм башкорт әдәбиятының күрке булган берешәр әсәрне һәр номерда бастыра башлый. Бу, беренчедән, ике республика, ике халык арасында милли-мәдәни алмашулар, аралашулар төрле сәяси сәбәпләр аркасында тыелган бер дәвердә, Башкортстанда яшәүче татар халкын Казанда яшәүче милләттәш-әдипләренең иҗаты белән таныштыра; икенчедән, башкорт әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен туган телдә уку мөмкинлеген тудыра. Шул рәвешле, Башкортстан татарлары Равил Фәйзуллин, Әхсән Баян, Мөдәрис Әгъләмов, Роберт Миңнуллин, Галимҗан Гыйльманов, Ркаил Зәйдулла, Харрас Әюп, Фәиз һәм Ләис Зөлкарнәйләр, Рашат Низами, Ленар Шәех һәм башка бик күп татар язучыларының иҗаты белән таныша; шул ук вакытта Равил Бикбаев, Хәсән Назар, Рамил Янбәк, Сабир Шәрипов, Рамил Кол-Дәүләт, Салават Әбүзәр, Дамир Шәрәфетдинов, Гыйльман Ишкинин, Азамат Юлдашбаев, Гөлназ Котыева, Лариса Абдуллина кебек башкорт әдипләренең әсәрләрен татар телендә уку мөмкинлеген ала. Бу ике халык, ике мәдәният арасында бәйләнешләрне ныгыту өчен үтемле чара була. Бу кагыйдә бүген дә үзгәрешсез кала.

Сан саен «Чәчмә әсәр» һәм «Шигърият» рубрикалары астында Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар авторларының 2-3 хикәясе һәм

шигъри шәлкеме басылып килә, «Илһамлы каләм» рубрикасында 2-3 кыска күләмле нәсер нәшер ителә. Журналда дөнья күргән шигырьләрнең сыйфаты турында Башкортстанның халык шагыйре Назар Нәҗмидән дә төгәлрәк әйтеп булмый. «Тулпар» да җирле үзешчән шагыйрь Мариус Максютовның шигырьләрен укыгач, ул алар турында зур рецензия язып, «Кызыл таң» газетасында бастыра. Анда шундый сүзләр урын ала: «Дистәләгән шигырь җыентыгын чыгарырга мөмкин, тик бу синең шагыйрь икәнлегеңне аңлатмый әле. Ләкин, әгәр «Тулпар» синең шигъри әсәрләреңне үз битләрендә бастырып чыгарырга лаек дип таба икән, димәк, син – шагыйрь!». Минемчә, яңа чыга башлаган басмага моннан да җылырак сүз әйтеп булмый. Шуны да өстик, халык шагыйренең журналга карата чиксез хөрмәте хакында Нажар Нәҗминең үлеменнән соң аның эш өстәлендә ике журналның – «Казан утлары» һәм «Тулпар»ның ачык килеш калуы да сөйли. Хәтта үлем газапларын кичергәндә дә шагыйрь яраткан басмаларыннан аерылмый... [2; 62]

Журналның 26 ел эчендә тупланган саннарын системалы рәвештә күздән кичерсәң, «Әдәби тәнкыйть» рубрикасы астында язмаларның акрынлап кимүен һәм эчтәлеге ягыннан саегуын күрергә мөмкин. 1990 еллар ахыры – 2000 еллар башында «Тулпар»да Суфиян Поварисов, Суфиян Сафуанов, Камил Дәүләтшин, Сәгыйдулла Хафизов, Лилия Сәгыйдуллина, Рәүф Идрисов кебек гыйльми дәрәҗәле, тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр күпләп чыгыш ясаса, соңгы 10 ел эчендә аларның кайсылары бакыйлыкка күчте (мәсәлән, Суфиян Поварисов, Суфиян Сафуанов, Камил Дәүләтшин), кайсылары журналдан читләште (мәсәлән, Сәгыйдулла Хафизов, Лилия Сәгыйдуллина, Рәүф Идрисов). Дөрес, алар урынына Альбина Хәлиуллина, Дилбәр Сөләйманова, Илдус Фазлетдинов, Руслан Сөләйманов кебек сәләтле яңа буын тәнкыйтьчеләре килде, ләкин аларның активлыгы түбән. Журналда 1990 – 2000 еллардагы «Шигырь кемгә кирәк?», «Җырның ертыгы бармы», «Башкортстан татар шигърияте: торышы һәм киләчәге» кебек актуаль темаларга сөйләшүләр дә уздырылмый. Димәк, «Тулпар» яшь буыннан, студентлардан тәнкыйтьчеләр үстерү белән шөгыльләнми. Дөрес, әдәбиятка, мәдәнияткә игътибар кимеп, алар коммерцияләшкән бүгенге дәвердә моның өчен гаепне бары тик редакциягә генә ташлау шулай ук дөрес түгел. Заманыбызга хас күренеш бу.

«Әдәби кунакханә» рубрикасында дөнья күргән язмаларда күренекле татар һәм башкорт әдипләре белән очрашулар, әңгәмәләр урын ала. Гадәттә, аларга иң четерекле сораулар бирелә, соңыннан «Тулпар»да дөнья күргән мондый әңгәмәләр буенча иң югары хакимият даирәләрендә фикер алышулар булуы да мәгълүм. Журнал битләрендә мондый сынауны Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Рафис Корбан, Галимҗан Гыйльманов, Марат Кәбиров, Наил Гаетбай, Риф Мифтахов, Марсель Сәлимов һәм

башка язучылар үтте. Язмалар кызыклы, халык, аеруча укытучылар тарафыннан яратып укыла.

«Иҗат берләшмәләрендә» һәм «Укучылар иҗаты» рубрикаларында дөнья күргән язмалар, нигездә, Башкортстанның төрле районнарында татар телендә проза һәм поэзия әсәрләре иҗат иткән үзешчән авторларга һәм әдәби берләшмәләргә багышлана. Сыйфат ягыннан алар һөнәри язучылар язган әсәрләрдән шактый калышса да, шул төбәкләрдә яшәүчеләр тарафыннан яратып укыла һәм анда «Тулпар» тиражларны арттыру өчен хезмәт итә.

**Әдәбият**

1. Фазлетдинов И.К. «Тулпар» ничек туды?: журналның беренче баш мөхәррире Римат Кашапов белән әңгәмә // Тулпар. – 2019. – № 5. – Б. 2-3.

2. Фазлутдинов И.К. На крыльях «Тулпар»а // Журналы Башкортостана / сост. Ахмадиев Ф.В.; Башкирский государственный университет. Кафедра журналистики; Управление по делам печати, изд-ва и полиграфии при Правительстве Респ. Башкортостан. – Уфа, 2004. – С. 62-71.

© Фазлутдинов И.И., 2021

УДК 821.512.145

**И.К. Фазлутдинов**

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ОБЪЕКТЫ БУЛАРАК БАШКОРТСТАНДАГЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ
# ТАТАРСКАЯ ПОЭЗИЯ БАШКОРТОСТАНА КАК ОБЪЕКТ ЛИТЕРАТУРНОЙ КРИТИКИ

***Аннотация:*** *В данной статье рассматривается проблема национальной идентичности татарской поэзии Башкортостана. Опираясь на материалы литературной критики, автор исследует индивидуальный стиль наиболее значимых поэтов, тем самым выявляя общие черты татарской региональной литературы.*

***Ключевые слова:*** *журнал, литература, направление, поэзия, реализм, романтизм, литературная критика, индивидуальный стиль.*

Татар әдәбиятының һәрдаим тормышка якын торып, халык һәм милләт язмышын үзәктә тотуы аның реалистик һәм романтик юнәлешләрдә үсүен билгели. Башкортстандагы татар поэзиясе дә бу хәрәкәттән аерылгысыз.“Иҗат иясенең индивидуаль стиле тормыш